**«Бэзэкэм, туган бишегем». Отклики в СМИ**

В газете Всемирного конгресса татар «Халкым минем» №2(69) от февраля 2017 года размещен репортаж с автором книги об истории села Бизяки «Бэзэкэм, туган бишегем» А.Х.Махмутовой. предлагаем этот материал вниманию наших читателей.

# «Бәзәкәм, туган бишегем»

***Шөкер, соңгы вакытта туып-ускән авыллары тарихы белән кызыксынучылар артты. Үзешчән тарихчылар бу җитди эшкә озак уйлап тормыйча тотынса, һөнәри тарихчылар, бик җаваплы эш бит дип, моңа шактый еллар әзерләнә, төпле документлар кулга кермичә алынмый. Галимә Альта ханым МӘХМҮТОВА да ашыкмый. Дөрес, сиксән яшьлек юбилеема туган авылым тарихын китап итеп чыгарам дигән максат куя. Февраль башында ул шул хезмәтен, «Бәзәкәм, туган бишегем» дигән китабын туган җирендә — Менделеев районының Бәзәкә авылында тәкъдим итү кичәсе уздырды. Шул уңайдан без аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.***




**Әлеге китапны язарга алыну теләге кайчан туды?**

— 2003 елда Иж-Бубый авылы һәм бертуган Бубыйлар турында китабым чыккан иде. Шул китап дөнья күргәч, авылдагы туганнарым, дусларым, авылыбыз турында да китап язарга вакыт җиткәндер инде, дип мөрәҗәгать итте. Эшнең никадәр авыр икәнен белгәнгә, мин моңарчы туры җавап бирүдән кача килдем. Ләкин архивларда утырганда, әлбәттә, Бәзәкәгә кагылышлы документларны да эзли идем. РГАДАда (Россия дәүләтенең борынгы актлар архивы) утырганда ук берничә документка юлыктым. Ул вакытта китап язарга уйламыйча, укытучыларга күрсәтергә дип кенә алып кайттым. Минем тема түгел дип һаман кичектереп килдем. Югыйсә мин үзем Казан университетында 1965 елдан 2010 елга кадәр, ягъни 45 ел тарих укыттым. Инде менә пенсиягә чыккач, күптән җыенган эшкә алынырга мөмкинлек туды.

**Бу ничәнче китабыгыз?**

— Бер дистәләп җыела алар хәзер. Иң беренче китабым 1982 елда дөнья күргән иде. Ләкин аны урталай кисеп, яртылаш кыскартып нәшер итәргә туры килде. «Из истории борьбы за светское образование у татар» дигән кандидатлык диссертациям «Становление светского образования у татар» дигән исем астында дөнья күрде. Гыйльми эшемдә мәгърифәтче Бубыйлар турында бүлек бар иде. Тик ул чак — Бубыйлар иң зур милләтчеләр булып саналган заман. Миңа Бубыйлар турындагы өлешне төшереп калдырырга куштылар. Ләкин мин анда барыбер Бубый мәктәбен калдырдым. Аны тулысынча ике дистә елдан соң гына бастыру насыйп булды. 1978 елда әзер иде инде ул. Тик дүрт елдан соң гына чыгардылар. Шуңа күрә бүтән китап язмаска булган идем. Докторлыкка да кул селтәдем. Дөньяда кызык нәрсәләр күп, докторлыкны язмыйча да яшәрмен дидем. Әмма мәкаләләр яздым, конференцияләрдә катнаштым, галим икәнсең, шунсыз булмый. Инде үзгәрешләр башлангач, 2001 елда (Бубыйлар, алдынгы фикерле хатын-кызларыбыз турында бик күп материал җыйган идем) болай җыеп яткыру дөрес булмас, дип, китап язарга утырдым. Мөгаен, компьютер уйлап тапмасалар, бер китабым чыкмаган килеш калган булыр идем. Чөнки компьютерда язу бик мавыктыргыч. Анда күпме кирәк шул кадәр төзәтә аласың. Фикерең ошамаса, яңадан язып ташлыйсың. Шулай итеп, 2003 елда Бубыйлар турында калын гына китабым чыкты. «Лишь тебе, народ, служенье!» дип атала ул. Аның татарчасы чыкмады. Мин аны урысча яздым. Чөнки татарчам шактый нык аксый. Мин башлангыч мәктәптә генә татарча укыдым.

**Димәк, пенсиягә чыгуга хыялыгызны тормышка ашыруга, авыл тарихын язуга тотындыгыз?**

— 2003 елда әле мин «Милләт аналары» дигән башка китабымны яза идем. «Шәхесләр» сериясеннән чыгар дип миңа шушы эшне кушкан иде Миркасыйм Госманов. Менә шушылай олыгайган көнемдә туган телебезне өйрәнүгә ныклап алындым. Без бит 1989 елда КДУда татфакны оештырдык. Шунда без Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә татар халкы тарихы кафедрасы оештырдык. Без шунда татар тарихын — татарча, урыс тарихын урысча укытырга дип сөйләштек. Үзең тәкъдим иткәнне үзең ничек үтәмисең инде?! Шулай итеп телемне дә чарладым (хәер, татар әдәбиятыннан болай да аерылмадым), язарга да өйрәндем. Дөресен әйткәндә, баштагы мәлләрдә материал булмас дип курыккан идем. Әмма максатчан эзләнә башлагач, материал күп икәнлегенә инандым. Хәер, Иж-Бубый турында китап язганда ук авылыбыз тарихын язарга алынган кешегә ярдәм булыр дип, «Ревизская сказка»лардагы Бәзәкә хакындагы мәгълүматларны җыеп бара башлаган идем. Тик өч ел узды, теге китап чыкмады. Шулай итеп, 2011-2012 елларда мин максатчан материал җыя башладым. Авыл тарихына тотыныйм гына дим, әле тегендә, әле монда Бубыйларга багышлап уздырыла торган конференцияләргә чакыралар. Ул арада — 2012 елда әле мин «Милләт аналары»на охшаган «Вакыт инде, без дә торыйк» дигән китап чыгардым. Аннан соң әле Габдулла Бубыйның «Хатыннар» дип аталган бик фәлсәфи, тирән эчтәлекле әсәрен әзерләп бастырдым. Аны урысчага тәрҗемә итеп укытучылар өчен дә нәшер иттек. Пенсиягә чыккач бастырган бишенче китап булып чыга бу. Алты елда бишенче китап — аз түгел бит! Әле менә хәзер Бәзәкәгә багышланган китабымның урысчасын тәмамлап киләм. Дөрес, мин аны башта ике телдә чыгармакчы идем. Бу китапны кем өчен язасың — анысын да уйларга кирәк! Әгәр дә өлкәннәр өчен язсаң, татарча кирәк. Яшьләр өчен язсаң — күбесенең оныгы Чаллы, Түбән Кама, Алабугада үсә — аңламаска мөмкиннәр. Сер түгел, хәзер аларның байтагы татарча сөйләшә белсә дә, татарча укый алмый бит. Димәк, урысча да кирәк. Тик бик калын булырга мөмкин икән. Барысы 500 биткә сыяр дигән идем, бер телдәгесе биш йөзгә җитте. Әллә инде кыска итеп яза алмыйм, белмим.



**Архивта утырганда төрле гыйбрәтле документлар да очрагандыр?**

— Чынлап та, кызыклы табышлар байтак булды. Әйтик, Бәзәкәнең XX гасыр башы тарихын эзләгәндә әти язган документларга тап булдым. Архивта эшләп кайтам да, сеңелләрем Әнисә белән Алисага шалтыратып: «Мин бүген әти белән күрешкәндәй булдым», — дип әйтә идем. Әтием 1920-1930 елларда авыл советы секретаре булып эшләгән. Шул чорда гарәп, латин, кириллицада язган язулар сакланган. Ул вакытта күп кенә документлар аның кулы белән язылган. Аларны уку, чынлап та, миңа әти белән очрашу кебек тоелды. Хатирәләрне яңартты, шулай миңа ярдәм итте. Китап язганда шушы Бәзәкәдә яшәүче Шәргыя апа һәм аның гаиләсе, сеңлем Әнисә һәм аның гаиләсе даими ярдәм итеп торды.

**Үзләре авыл тарихын язарга уйлаганнарга нинди киңәшләр бирер идегез? Нәрсәдән башларга? Менә кайбер авторлар хәзерге заманнан борынгы заманга барырга киңәш итә, кайберәүләр, киресенчә, борынгыдан бүгенгә килергә кирәк, ди.**

— Минемчә, эшне архивлардан, борынгыдан башларга, әкренләп бу заманга килергә кирәк. Шулай да әүвәл РГАДАга барырга киңәш итмәс идем. Андагы документларны укыр өчен белем кирәк. Борынгы славян язуын укуы бик авыр. 1719 елны чыккан беренче «Ревизская сказка»дан башлап 1858 елда чыккан соңгысына кадәр карарга кирәк. Һәрхәлдә, аларның XIX гасырга караганнарын аңлавы кыен түгел. XVIII гасырны аңлавы читенрәк. Менә шул XIX гасырдагысыннан башлау дөресрәктер. Алар Казанда, Уфада, Мәскәүдә дә бар. Боларына күнеккәч, борынгыраклярын өйрәнә башларга мөмкин. Миңа җиңелрәк булды. Мин кечкенә чакта авыл шәҗәрәсен Таҗимулла абзый Шакиров төзегән иде. Тарихка алып кереп китүче беренче остазым булды ул. Мин бик кызыксынучан, үҗәт бала идем. Ул миңа шәҗәрәнең, нәсел чылбырының нәрсә икәнен аңлатты. Әмма үсә башлагач, кызыксынулар икенче юнәлешкә китте, шәҗәрә дә онытылды. Инде туксанынчы елларда, авылга ялга кайткач, укытучылар белән сөйләшкәндә борынгы тарих еш кузгатыла башлады. Табигый, мин тарихчы галимә булгач, туган ягыбыз тарихына кагылышлы сораулар да бирәләр. Шулай авылыбыз шәҗәрәсе булуы искә төште. Бер өлкән укытучыбыз — Фәйзелхак абый аны күчереп алып кайтарып бирү шарты белән бер галимнең Казанга, Тел, әдәбият һәм тарих институтына алып китүен әйтте. Шуннан соң егерме ел узган, кайтарып бирүче булмаган. Әлеге галим минем танышым булып чыкты, аңардан авылыбызның шәҗәрәсен кире алдым. Хәзер ул Фәйзелхак абыйның малаенда саклана. Китабымда безнең нәселгә караучы бер бите бирелде.

**Гадәттә, нәсел-шәҗәрәләр авылдагы ун-унбиш гаиләгә кайтып кала, шулардан башкалары таралган диләр. Шул дөресме? Болай раслау Бәзәкәгә туры киләме?**

— Дөрес булырга тиеш. Әгәр 1517 елга килсәк, авылга нигез салучылар 6-7 кешедән артмагандыр дип уйлыйм. Ләкин XVIII гасырдагы исемнәрне XIX гасырдагы исемнәр арасыннан табып булмый. Менә мин таптым, анда да әтидән җиде буын бабамнарның исемнәрен белгәнгә күрә генә (болар — Мәхмүт, Ибраһим, Бикташ, Хуҗаш, Уразмәт, Тәкәш, Сөләйман). Буыннар өзелергә мөмкин. Әйтик, менә синең фамилияң Минһаҗ да бит, әмма алдагы буыннарда әлеге исем фамилия булып бармаган. Ата исеме генә язылган. Шуңа күрә Сөлеков Хуҗаш, Хуҗашев Бикташ, Бикташев Ибраһим, Ибраһимов Мәхмүт, Мәхмүтов Хаҗиәхмәт дип фамилия гел үзгәреп торган. Моны белсәң, табасың. Менә Бикташның энесе Хисмәтулла исемле булган. Мин аларның очына чыгып җитә алмадым әле. Алар Хисмәтуллиннар булып киткән. 1858 елга хәтле җиткердем мин аларны. Әмма XIX гасырның икенче яртысында, 1858 ел белән 1896 ел арасында «Ревизская сказка»лар юк. 1897 елда Бөтенроссия халык санын исәпкә алу уздырыла. Кырык ел эчендә ике буын алмашынырга мөмкин. Димәк, атасының фамилиясе калмый, инде бу кешенең кайсы Хисмәтулла малае икәнен белеп булмый. Шундый авырлык бар.

**Әле бит шунысы да бар. Күп кенә авылларда кешеләр 4-5 гасыр буе яшәмәгән, күченеп тә йөргән. Сездә ничек булган?**

— Минемчә, безнекеләр күчеп китеп, кире кайтып йөрмәгән. Чөнки алар шушы җирләрнең хуҗалары булып теркәлгән. Безнекеләр читтән дә кеше кертмәгән. Үзләре, дә һәрхәлдә, соңгы өч гасырда күченеп китмәгән. Дөрес, башкорт сословиесенә язылып, үзләренә ташлама-льготалар алганнары билгеле.




**Авылыгызга нәкъ менә 1517 елда нигез салынуны раслаучы документлар бармы?**

— Җирне беркетүче әлеге документ юк, ул янган. Бу — минем фаразлау гына. Ләкин андый дата бар. 7025 елгы (элеккеге христиан ел исәпләве, хәзергечә 1517 гә туры килә) документ эштә теркәлмәгән, дигән искәрмә бар архив документларында. Бәзәкә җирләрен бу тирәдән узып баручы теләсә кемгә бирмәгәннәр бит. Димәк, беренче булып бу җирләрне үзенә теркәттергән кеше Тагай Белековмы, Беләковмы булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килдем мин. Ул вакытта Мәскәү кенәзлеге тәхетендә — Василий III, Казан ханлыгы тәхетендә Мөхәммәтәмин хан утырган. Кайсы бирергә мөмкин? Мөхәммәтәминнең дә ярлыклары бар. Василий Өченченең дә жалованный грамоталары бар. Ул 1510 елдан башлап ар кенәзләренә берничә грамота бирә. Нократ, Иж буйларына, нәкъ менә шушы җирләргә туры килә бу, минемчә. Шулар арасында безнең Тагай-Таһир баба да булырга мөмкин дип уйлыйм мин. Авыл биләмәләренең чикләре ачык күрсәтелгәч, Таһир баба бу җирләрне элегрәк тә белгән булып чыга. Минем фаразлавым буенча, Аксак Тимер яуларыннан качып, болгар җирләреннән бирегә килеп урнашканнардыр дип уйлыйм. Бәзәкәгә шул чорда нигез салынган, минемчә. Таһир баба шул нигез салучыларның берсе булган. (Дөрес, бу җәһәттән тарихчы Дамир Исхаков башка фикердә. XVI гасыр башында бу җирләр Казан ханлыгы биләмәсендә булып, әүвәл Мөхәммәтәмин хан ярлык биргәндер, урыс патшаларының саклагыч грамотасы соңрак алынгандыр, дип исәпли ул. — *Р. М.*)

**Димәк, биш йөз еллыкны уздырырга була?**

— Әйе, быел җәен ике датаны бәйрәм итәргә мөмкин. Берсе аның миңа сиксән яшь тулу булса, икенчесе — авылның биш йөз еллыгы. Безнең авыл халкы бик тату, бердәм. Халык алынса, бөтен эшне дә башкарып чыга ала. Туган көнем — ул инде шәхси бәйрәм. Минем өчен, туганнарым өчен бәйрәм. Ә менә авылның туган көнен уздырсак, барча халык өчен бик күңелле булыр иде.

*Әңгәмәдәш — Рәшит МИНҺАҖ.*